**СОВЕТ КУРКАЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422730, Республика Татарстан, Высокогорский район, п. ж/д. рзд. Куркачи, ул. Гагарина, 7

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОРКАЧЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422730, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Коркачык тимер юл разъезды поселогы, Гагарин урамы, 7

тел./факс 8(84365) 71-2-15, e-mail: Kurk.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**18 сентябрь 2025 ел** **№ 1**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башлыгын сайлау турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 89 статьясы, Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге Уставының 43 һәм 44 статьялары нигезендә, Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Коркачык авыл җирлегенең 9 нчы бермандатлы сайлау округы депутаты Гәрәев Данис Рафил улын «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башлыгы һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Коркачык авыл җирлеге Советы рәисе итеп сайларга.
2. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы вазыйфасына керешкән көн дип ул Биектау муниципаль районының Коркачык авыл җирлеге Советы депутатлары составыннан сайланган көнне санарга.
3. «Җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясындагы 1 өлеше һәм Биектау муниципаль районының Коркачык авыл җирлеге Уставының 43 статьясындагы 5 өлеше нигезендә Гәрәев Данис Рафил улын Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе итеп билгеләргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының интернет челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru.

Рәислек итүче Л.А. Бандорина